ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.01.2019 3

Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне уздыруны раслый торган документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының "Муниципаль учреждениеләр һәм Алабуга муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 2012 елның 27 февралендәге 149 нчы санлы карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне башкаруны раслый торган документ бирү Кагыйдәләрен раслау турында" 2011 елның 18 августындагы 686 нчы санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне уздыруны раслый торган документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының "Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне уздыруны раслаучы документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2013 елның 07 июлендәге 896 нчы карарын көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең архитектура һәм шәһәр төзелеше буенча урынбасары О.А. Никитинага йөкләргә.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин